СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2019ел. с. Сарманово № 171

Сарман муниципаль районы Советының 2017 елның 28 сентябреннән 87 номерлы "«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән бердәнбер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керү өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" гы карарына үзгәреш кертү турында

"Гражданнарның үз ихтыяжлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 29 июленнән 217-ФЗ номерлы Федераль законы (03.08.2018 елгы редакциясе), Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман муниципаль район Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Советының 2017 елның 28 сентябреннән 87 номерлы "«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән бердәнбер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керү өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" гы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 1 пунктта "бакчачылык, яшелчәчелек, дача куллануӵылар кооперативлары" сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (pravo.tatarstan.ru) һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы "Сарман муниципаль районы" муниципаль берәмлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Элеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы рәисе Ф.М.Хөснуллин